ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 июнь, 2023 ел № 25/10

Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

**КАРАР** бирде:

1. Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә (Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы 26/11, 2019 елның 25 февралендәге 30/6, 2019 елның 1 августындагы 32/11, 2020 елның 17 июнендәге 40/6, 2021 елның 18 мартындагы 6/12, 2021 елның 3 ноябрендәге 9/9, 2022 елның 23 июнендәге 15/10 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) преамбулада «Россия Федерациясе Төзелеш министрлыгының 2017 елның 13 апрелендәге «Җирлекләр, шәһәр округлары, шәһәр эчендәге районнар территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләрен әзерләү өчен методик рекомендацияләрне раслау турында» 711/пр санлы боерыгына» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 6 пунктта:

- 36 – 38 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«36) элмә librosтакталар урнаштыру дизайн-проекты (тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проекты (паспорты)) - мәгълүмат тактасын урнаштыруның тышкы күренешен, төгәл урынын билгели торган һәм аны идентификацияләү өчен кирәкле башка белешмәләрне үз эченә алган билгеләнгән формадагы документ;

37) мәгълүмати элмә такта (тышкы мәгълүмат чарасы) - оешма урнашкан урында: бинаның фасадында - бинага керү ишеге янында (керү ишегеннән уң якта яисә сул якта), яки оешма эшчәнлеген алып барган бинаның оешма урнашкан бүлмәләре тәрәзәләре чикләрендә, шулай ук әлеге бинаның тәрәзә уемнарының

өске яки аскы ягында, яки оешма эшчәнлеген алып барган бина фасадының үз участогы өлешендә тышкы стенасы чикләрендә, һәм (яисә) товар сату, хезмәт күрсәтү урынында төзелеш һәм корылмаларны, шул исәптән, капиталь булмаган корылмаларны мәгълүмати бизәлеш максатларында фасадның тышкы стенасы чикләрендә урнаштырылган территорияне төзекләндерү элементы;

38) реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны урнаштыру концепциясе - төзелгән төзелешнең тышкы архитектура кыяфәтен саклау максатыннан Башкарма комитетның вәкаләтле органы белән килештерелгән һәм шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырылган конкрет объектта (бина, төзелеш, корылма) реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмат такталарын урнаштыру проекты;»;

- 40 – 41 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«40) штендер - бер яки ике мәгълүмати яки реклама өслеге булган күчмә мобиль конструкция;

41) режимлы табличка – оешманың фирма исеме (исеме) һәм аның эш режимы турында мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмати элмә такта;

3) 9.14 пунктның 21, 22 пунктчаларын көчен югалткан дип танырга;

4) 21, 21.1. бүлекләрне яңа редакциядә бәян итәргә:

«21 бүлек. Реклама конструкцияләре һәм мәгълүмати элмә такталар

115. Реклама конструкцияләрен, шулай ук башка график элементларны урнаштыру «Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Башкарма комитет тарафыннан расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзү хокукына сатулар ачык аукцион һәм конкурс рәвешендә уздырыла

116. Мәгълүмати элмә такталарны урнаштыруны (режимлы табличкалардан тыш) әлеге объектта урнаштыру хокукы бирә торган шартнамәнең гамәлдә булу срогына, әмма биш елдан артык булмаган вакытка, реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмат такталарын урнаштыру концепциясен урнаштыру дизайн-проекты нигезендә гамәлгә ашырырга кирәк.

Биналар, төзелмәләр, корылмалар фасадында мәгълүмати элмә такта урнаштыру вариантлары һәм урнаштыруга таләпләр Башкарма комитет карары белән раслана.

Мәгълүмати элмә тактаның дизайн-проектын килештерү, әлеге объектта урнаштыру хокукы бирә торган шартнамәнең гамәлдә булу срогы тәмамланган очракта һәм (яисә) мәгълүмати элмә тактаның реклама конструкцияләрен урнаштыру концепциясенә туры килмәгән очракта, юкка чыгарыла.

116.1. Объектта реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталар урнаштыру урыны реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны урнаштыру концепциясе белән билгеләнә.

117. Реклама конструкцияләре һәм мәгълүмати элмә такталар төзек инженер-техник хәлдә булырга, рөхсәт бирү һәм проект документациясенә туры килергә, эстетик күренешле һәм чиста булырга, өслекләрендә чит язмалар, рәсемнәр, белдерүләр, плакатлар, башка мәгълүмати - басма продукция һәм аларның өлешләре булмаска тиеш. Реклама конструкцияләрендә рәсемнәр тулы,

бозылмаган булырга тиеш.

Реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны проектлау, әзерләү һәм урнаштыру төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре таләпләре нигезендә, янгын куркынычсызлыгы таләпләрен исәпкә алып, гамәлгә ашырылырга тиеш.

Реклама конструкциясе яки мәгълүмати элмә такталар хуҗасы монтажлау тәмамланган вакыттан алып өч тәүлек эчендә территорияне төзекләндерә һәм (яисә) фасадның тышкы кыяфәтен тәртипкә китерә.

Реклама конструкциясе яки мәгълүмати элмә такталарны сүтеп алу объектта урнашуга хокук бирә торган шартнамә тәмамланганнан соң реклама конструкциясе яки мәгълүмати элмә такта хуҗасы тарафыннан тәүлек дәвамында башкарыла. Фундамент блогы булган реклама конструкциясе яки мәгълүмати элмә такта фундамент блогы белән бергә сүтеп алына.

Реклама конструкциясе яки мәгълүмати элмә такта урнаштырганда корылмаларга һәм объект бизәлешенә зыян китерү, шулай ук аларның бөтенлеген, ныклыгын һәм тотрыклылыгын киметү рөхсәт ителми.

Реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны тиешенчә карап тормаган, шулай ук конструкцияләрне монтажлау һәм эксплуатацияләү шартларын бозу сәбәпле барлыкка килгән җитешсезлекләр һәм авария хәлләре өчен реклама конструкцияләре һәм мәгълүмати элмә такталар хуҗалары җаваплы.

118. Рекламада рәсем булмаганда, биналарда, корылмаларда урнашкан щитлы реклама конструкцияләре өслеге, шулай ук аерым реклама конструкцияләре өслеге якты төскә буялган щитлар белән ябыла, яки якты төстәге материал белән тарттырыла.

119. Реклама конструкцияләре һәм мәгълүмати элмә такталарның металлдан ясалган элементлары буялган һәм коррозиясез булырга тиеш. Реклама конструкцияләре һәм мәгълүмати элмә такталарның таш яки бетоннан, агачтан ясалган элементлары буялган булырга тиеш, декоратив бизәлештә таш яки агачның табигый төсләрен куллану очракларыннан тыш. Реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны буяу 1 майга кадәр, елга бер тапкырдан да ким булмаган ешлыкта, зарурлыктан чыгып башкарыла.

120. Рөхсәт ителми:

1) Башкарма комитетның вәкаләтле органы тарафыннан бирелгән реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә рөхсәтсез реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү;

2) мәгълүмати элмә такта урнаштыру дизайн-проекты Башкарма комитетның вәкаләтле органы тарафыннан килештерелмәгән мәгълүмати элмә такта урнаштыру һәм эксплуатацияләү;

3) Башкарма комитетның вәкаләтле органы тарафыннан килештерелгән мәгълүмати элмә такта дизайн-проектына туры килми торган мәгълүмати элмә такта урнаштыру һәм эксплуатацияләү;

4) зыян күргән рәсемнәре (рәсем бөтенлеге, язу бөтенлеге бозылган һ.б.) булган реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны ике тәүлектән артык эксплуатацияләү;

5) механик зарарланган (конструкция деформациясе, зыян күргән щит һ.б.) реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны эксплуатацияләү;

6) мәгълүмат-басма продукцияне һәм реклама продукциясенең башка

төрләрен әлеге максатлар өчен билгеләнгән урыннардан тыш урнаштыру;

7) конструкциянең бер төрен кулланып мәгълүматны кабатлый торган реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталар урнаштыру һәм эксплуатацияләү, моңа түбәндәгеләр керми:

- Россия Федерациясе дәүләт теле һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы законнар таләпләрен үтәү йөзеннән бирелгән мәгълүмат;

- берничә урам киселешендә яисә ике урам арасындагы территориядә урнашкан бинаның һәр фасадында урнаштырылган мәгълүмат;

8) режимлы табличкадан тыш, алыштырыла торган рәсемле мәгълүмати элмә такта урнаштыру;

9) яктыртуның ачык ысулын кулланып, мәгълүмати элмә такталар урнаштыру;

10) биналарда тәрәзә уемнарын, витрина пыялаларын, тәрәзәләрне, аркаларны, архитектура детальләрен һәм декоратив-сәнгати бизәлешне каплаган мәгълүмати элмә такталар урнаштыру.

121. Газета, плакат, афиша, белдерүләрне, реклама проспектларын һәм башка мәгълүмати-басма продукцияне ябыштыру махсус билгеләнгән щитларда, стендларда яки тумбаларда гына рөхсәт ителә.

122. Мәгълүмати элмә тактада мәгълүмат Россия Федерациясе дәүләт теле һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы законнар таләпләренә туры китереп урнаштырылырга тиеш.

Ике һәм аннан да күбрәк тел кулланылган очракта текстлар эчтәлеге һәм техник бизәлеше буенча тәңгәл килергә, дөрес һәм аңлаешлы итеп язылырга тиеш.

## 21.1 бүлек. Режимлы табличкалар урнаштыру тәртибе

122.1. Режимлы табличкалар әлеге мәгълүмат конструкциясендә мәгълүмат урнаштырылган оешма яисә шәхси эшмәкәр фактта урнашкан (эшчәнлек алып барган) бинаның, төзелмәнең, корылманың керү ишегенә, һәркем күрерлек итеп, фасадның архитектура элементларыннан буш булган яссы участокларында, турыдан–туры керү урынында (уң яки сул якта) урнаштырыла.

122.2. Бер объектта оешма, шәхси эшмәкәр өчен бер режимлы табличка куелырга мөмкин.

122.3. Режимлы табличка белән җир өслеге (керү урыны идәне) арасы 2 метрдан артмаска тиеш.

122.4. Режимлы табличка фасад яссылыгы чикләрендә башка шундый ук мәгълүмаи элмә такталар булган бердәм горизонталь үзәктә урнаштырыла.

Режимлы табличка мәгълүмат кырыннан (текст өлешеннән) тора.

Элмә тактаның рөхсәт ителгән зурлыгы:

киңлеге буенча 0,50 м дан артык түгел;

биеклеге буенча 0,60 м дан артык түгел.

Шул ук вакытта хәрефләрнең, билгеләрнең биеклеге 0,10 м дан артмаска тиеш.

122.5. Бер объектта берничә оешма, шәхси эшмәкәр урнашкан очракта, объект фасадларында бер керү урынында урнаштырыла торган режимлы табличкаларының гомуми мәйданы 2 кв. метрдан артмаска тиеш.

Шул ук вакытта бер керү урынында урнашкан табличкалар параметрлары бертөрле булырга һәм 122.4 пунктының өченче абзацында билгеләнгән зурлыктан

артмаска тиеш, җир өслегеннән (керү урыны идәненнән) мәгълүмат табличкасының өске ягына кадәр ераклык 2 м дан артмаска тиеш.

122.6. Режимлы табличкалар витринаның пыяла өлешенә трафарет белән бастырылып урнаштырылырга мөмкин.

Шул ук вакытта күрсәтелгән табличкаларның озынлыгы – 0,30 м, биеклеге – 0,20 м дан артмаска тиеш.

122.5 пунктының беренче абзацында күрсәтелгән очракта, витрина пыяласына берничә табличка урнаштыру рөхсәт ителә, табличкаларның гомуми саны дүрттән дә артмаска, алар арасында ераклык 0,15 метрдан да ким булмаска тиеш.

122.7. Мәгълүмат табличкаларында мәгълүмат Россия Федерациясе дәүләт теле һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы законнар таләпләренә туры китереп урнаштырылырга тиеш.

Ике һәм аннан да күбрәк тел кулланылган очракта текстлар эчтәлеге һәм техник бизәлеше буенча тәңгәл килергә, дөрес һәм ачык итеп эшләнгән булырга тиеш.»;

5) 125.1 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) стационар булмаган сәүдә объектларында мәгълүмати элмә такталарны билгеләнгән тәртиптә килештерелгән мәгълүмати элмә такта урнаштыруның дизайн-проекты, мондый объектның проекты (паспорты) нигезендә урнаштыралар һәм эксплуатациялиләр.»;

6) 128 пунктның 3 пунктчасында «мәгълүмат табличкалары» сүзләрен «режимлы табличкалар» сүзләренә алыштырырга;

7) 138 пунктта «мәгълүмат табличкалары» сүзләрен «режимлы табличкалар» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыгын үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш.Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ